ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10.2020 ел Баулы шәһәре №205

2021 елга Баулы муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларының
норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15нче статьясы 1нче өлешенең 11нче пункты, Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 11 декабрендәге 201 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.

2. Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы түбәндәгеләр тарафыннан расланган гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

әлеге карарның 1нче пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 30 октябрендәге
205 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җире | 92 851 |
| | авыл җире | 94 213 |
| гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җире | 139 227 |
| | авыл җире | 143 701 |

______________